**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы**
**Түбән Биш авыл җирлеге Советы**

# КАРАР

**№ 152** **24 .06.2024 ел**

**Зәй муниципаль районы Түбән Биш авыл җирлеге башкарма комитеты баш бухгалтерының хезмәткә түләүне оештыру һәм шартлары турында 27.05.2019 ел № 168 Түбән Биш авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясенең 1998 елның 31 июлендәге 145-ФЗ номерлы Бюджет кодексына ярашлы рәвештә, Зәй муниципаль районы Түбән Биш авыл җирлеге, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Түбән Биш авыл җирлеге Советы Уставына таянып

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Зәй муниципаль районы Түбән Биш авыл җирлеге Советының 2019 елның 27 маендагы 168 нче номерлы карары белән расланган «Муниципаль хезмәт вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш, Зәй муниципаль районы Түбән Биш авыл җирлеге башкарма комитеты баш бухгалтерының хезмәт хакын оештыру һәм түләү шартлары турында нигезләмәнең» (22.09.2020 ел № 187, 22.11.2022 ел № 75, 24.06.2024 ел №135 Түбән Биш авыл җирлеге Советының үзгәрешләре һәм өстәмәләре белән), 2.2 пунктына үзгәрешләр кертергә, «Баш бухгалтер» һәм «Бухгалтер» юлларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| Баш бухгалтер | 25 700 сум | 27 000 сум |
| Бухгалтер | - | 24 500 сум |

2. Штат расписаниеләренә һәм локаль актларга тиешле үзгәрешләр кертергә.
3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» бастырып чыгарырга (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районы Түбән Биш авыл җирлегенең рәсми сайтында.
4. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Түбән Биш авыл җирлеге**
**Советы Рәисе** **А.Р.Гильфанова**